ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2019 Казан шәһәре № 10-146/кс

«Аммоний» акционерлык җәмгыяте өчен техник суга Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 21.11.2018 № 10-47/кс карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2020-2021 елларга техник суга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Аммоний» акционерлык җәмгыяте өчен техник суга 2019-2021 елларга тарифлар билгеләү турында» 21.11.2018 № 10-47/кс карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 21.11.2018 № 10-47/кс карарына 1 кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 02.12.2019 № 10-146/кс карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Аммоний» акционерлык җәмгыяте өчен техник суга 2019-2021 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Техник су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2021 ел | |
| | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр |
| | Менделеевск муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | "Аммоний" акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 12,22 | 12,54 | 12,54 | 12,89 | 12,89 | 13,26 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 21.11.2018 № 10-47/кс карарына 2 кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 02.12.2019 № 10-146/кс карары редакциясендә)

## Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Аммоний» акционерлык җәмгыяте өчен техник суга 2019-2021 елларга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | "Аммоний" акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Техник су | 2019 | 38671,21 | 1 | - | – | 0,68 |
| | | 2020 | 39433,02 | 1 | - | – | 0,68 |
| | | 2021 | 40483,12 | 1 | - | – | 0,68 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге